**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Глава**
**Микулинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

423306, Азнакаевский район,
с. Микулино, ул. Советская, д.74
тел.8(855-92)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Микулино авыл җирлеге**
**Советы**
**Башлыгы**

423306, Азнакай районы,
Микулино авылы, Совет урамы, 74
тел.8(855-92)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

« 15» ноябрь 2021 ел — №4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең Микулино торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Уставы белән, карарчыгарам:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Микулино авылында Совет урамы буенча 1 - 68 йортларда, Яңа урамы буенча 1 - 6 йортларда теркәлгән һәм сайлау хокукынаия гражданнар өчен 2021 елның 25ноябрендә 17 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халыкҗыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Микулино авылында Совет урамы буенча 78 - 108 йортларда теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 26 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә:.

3.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Микулино торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 25 ноябрь 2020 ел 17.00 сәг.тән 18.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 26 ноябрь 2020 ел 17.00 сәг.тән 18.00 сәг.кадәр;
- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Микулино авылы, Совет ур.74 йорт, Микулино авыл мәдәният йорты каршындагы мәйдан.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2021 елның 15 ноябреннәндә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Микулино авылы, Совет урамы, 74йорт;

Микулино торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүматчараларында һәм башка ысуллар белән Микулино торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәритәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарылаторган мәсьәләнерасларга:

«Сез 2022 елда Микулино авылҗирлеге Микулино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашу чылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сумкүләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 175 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм буакчаларның җирле әһәмият кәия булган түбәндәге сора уларныхәлитүгәюнәлтүбеләнкилешәсезме:

- Юлларны җәй көне карап тоту (юл буенда үләннәр һәм куаклар чабу );
- Кыш көне юлларны карап тоту (Микулино авылында юлларны кардан чистарту);
- Яңа урам буенча юл ремонты;
- "Сугыш чоры балаларына" һәйкәлен реконструкцияләү, коймаларны алыштыру;
- Урам исемнәре күрсәтелгән билгеләр кую һәм сатып алу (рус һәм татар телләрендә);
- Электр җиһазларын ремонтлау һәм урамнарны яктырту лампочкаларын алыштыру;
- су скважинасы өчен су астына төшүче насосны сатып алу һәм алыштыру;
- янгын сүндерү өчен яралар сатып алу (2 шт);
- Микулино авылында Совет урамы буенча 70 нче йортта ял итү зонасын төзү һәм төзекләндерү( коры агачларны һәм үләннәрне чабу һәм кисү, юлны туклаңдыру)
- Бәйрәмнәр оештыру һәм үткәрү («Сабантуй», «Авыл көне», «Өлкәннәр көне», «Яңа ел»)

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Микулин авылы, Совет ур., 74 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: И.А.Такиулин